# СЕБЕР ТӨБӘГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ДӨНЬЯ СУРӘТЕ

**Флера Сәгыйт кызы Сэйфуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш, Кремль ур., 18 нче йорт,
fsaifulina@mail.ru.

**Гөлфия Марат кызы Талипова,**
Тюмән дәүләт университеты,
Россия, 625003, Төмән ш., Семак ур., 10 нчы йорт,
gulfiya.talipova@yandex.ru.

**Flera Sagitovna Sayfulina,**
Kazan Federal University,
Russia, 420008, Kazan, Kremlyovskaya St., 18,
fsaifulina@mail.ru.

**Gulfiya Maratovna Talipova,**
Tyumen State University,
Russia, 625003, Tyumen, Semakova Str., 10,
gulfiya.talipova@yandex.ru.

Мәкалә себер җирлегендә иҗат ителгән татар әдәбияты үрнәкләрендә дөнья сурәтенең үзенчәлекле яктыртылышын күзәтүгә багышлана. Әдәби текстта чагылыш тапкан милли менталитетның характерлы сыйфатлары, авторның дөньяны индивидуаль кабул итү хосусиятләре себертатар язучылары – прозаик Якуб Зәнкиев, шагыйрьләр Булат Сөләйманов, Шәүкәт Гаделша – иҗатлары мисалында тикшерелә. Себер татарларының психологик портреты, яшәешенең мораль-этик кануннары, әйләнә-тирәгә, аеруча табигатькә үзгә мөнәсәбәте региональ сүз сәнгатенең әдәби сурәте үзәгендә тора. Халык иҗаты җәүһәрләре, төбәкнең бай тарихы һәм шәхесләре, кабатланмас мифологиясе дә дөнья сурәтен баетып киләләр.Аерым географик җирлектә язылып, шушы төбәк әдәбиятына гына хас булган уникаль сыйфатлар белән характерланган әсәрләр бербөтенне тәшкил итүче гомуммилли әдәби мирасның кабатланмас, үзенчәлекле бер өлеше буларак бәяләнә

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, себер татарлары, милли әдәбият, төбәк әдәбияты, әдәбиятта дөнья сурәте.

**Аннотация:** Статья посвящена исследованию проблемы создания своеобразного образа мира в образцах татарской литературы, созданной на территории Сибири. Характерные черты национального менталитета, которые нашли отражение в литературном тексте, особенности авторского индивидуального восприятия мира исследуются на примере творчества сибирско-татарских писателей – прозаика Якуба Занкиева, поэтов – Булата

Сулейманова, Шауката Гадельши. Психологический портрет сибирских татар, морально-этические каноны их бытия, своеобразное отношение к окружающему миру, особенно к миру природы находится в центре внимания регионального словесного искусства. Жемчужины народного творчества, богатая история края и известные личности, неповторимая мифология, впряженные в канву литературного произведения, влияют на исключительность образа мира, созданной литературоведами. Написанные на определенной географической территории, характеризованные уникальными свойствами, присущими только литературе данного края произведения анализируются как особенная состовляющая часть общенационального литературного наследия.

**Төп төшенчәләр**: татарская литература, сибирские татары, национальная литература, региональная литература, образ мира в литературе.

Әдәбият турында сүз алып барганда, «дөнья әдәбияты», «халык әдәбияты», «милли әдәбият» төшенчәләре белән бергә, соңгы елларда «региональ әдәбият» (төбәк әдәбияты) төшенчәсе дә кулланылышка керде. Татар халкы географик рельефы, табигате, көнкүреше, яшәү шартлары белән бер-берсеннән аерылып торган төрле регионнарда гомер итә. Бер географик җирлектә иҗат ителеп, үзенә генә хас уникаль сыйфатларны чагылдырган әсәрләр төбәк әдәбиятын тәшкил итә. Һәр төбәкнең әдәби мирасы гомуммилли әдәбиятның кабатланмас, үзенчәлекле, башкалардан аерылып торган бер өлеше буларак бәяләнә.

Гомуммилли әдәбият галимнәр тарафыннан җентекле өйрәнелгән булса, аерым төбәкләрдә иҗат ителгән әдәбиятларның үзенчәлекләрен тикшерү, нигездә, XX гасырның соңгы чирегендә актуальләште. Әдәби белем бирү системасында региональ компонентка йөз тоту, бу юнәлешкә игътибар көчәю, әдәби әсәргә яңача якын килү таләбе куелу – барысы бу юнәлешнең әһәмиятен тагын да арттыра. Региональ әдәбиятларны гыйльми күзаллауны максат иткән фәнни-гамәли конференцияләр дә, заман соравы буларак кабул ителеп, галимнәрнең эшчәнлеген активлаштырды.

«Әдәби перифириядән» – Россия төбәкләреннән чыгып, милли әдәбият тарихына үз исемен алтын хәрефләр белән язып калдырган әдипләр аз түгел. Башкортостан, Пенза, Саратов, Ростов-Дон, Сембер, Оренбург, Себер төбәкләре татар сүз сәнгатенә Шәмсетдин Зәки, Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Шәехзадә Бабич, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури,

Мирхәйдәр Фәйзи, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Гадел Кутуй, Мирсәй Әмир, Фатих Кәрим, Муса Җәлил һ.б. талантларны бирде. Соңгы елларда татар әдәбиятының, нигездә, Татарстанда һәм Башкортостанның татар районнарында туып-үсеп, милли белем алган һәм әдәби-тарихи шартларда формалашкан язучылар исәбенә генә баюы, һәм, киресенчә, регионнардан килеп кушылган әдәби үрнәкләрнең елдан-ел азая баруы, үзәктән читтә яшәп, милли әдәбиятны баетуга үз өлешләрен керткән аерым төбәк әдәбиятын төрле яклап фәнни өйрәнүнең зарурлыгын һәм актуальлеген раслый. Төбәк әдәбиятларына игътибарлы булу, аны үстерү өчен шартлар булдыру, бу әдәби мирасны гомуми әдәби барыш кысаларында өйрәнү, идея-эстетик кыйммәтен ачыклап, әдәби процесста аның тоткан урынын билгеләү – татар әдәбият белеменең әһәмиятле юнәлешләреннән берсе. Бу мәкалә, зур географик территорияне биләп, Себер якларының бер өлешен тәшкил иткән Төмән-Тубыл төбәге татар әдәбиятын өйрәнүгә багышлана.

Билгеле бер халык, этносның үзенчәлекле менталитеты чагылышы – милли әдәбиятның төп сыйфатларыннан берсе буларак санала. Милләтнең психологик портреты, яшәешенең мораль-этик кануннары, әйләнә-тирәгә мөнәсәбәтенең сурәте сүз сәнгатенең үзәгендә тора. Гуманлылык һәм гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөрү – татар әдәбиятының төп билгесе. Әлбәттә, тарихи башлангыч мондый әсәрләрнең асылын тәшкил итә: аларда халык тарихы һәм җәмгыятьнең үз тарихи үткәненә мөнәсәбәте чагылыш таба.

Әдәбият белемендә региональ әдәбият «язучыларның аерым җирлекне (гадәттә, авыл җирлеге) һәм бу җирлектә яшәүче кешеләрне сурәтләүгә игътибарны юнәлткән әсәрләрнең бердәмлеге» [1: 864][1] буларак тәкъдим ителә. Әдәбият галимнәре «матур әдәбиятта аерым бер урынчылыкка, өлкәгә генә хас булган милли яшәешне, табигать сурәтен, тел үзенчәлекләрен» яңадан тудыруга омтылган «җирле колорит» төшенчәсен дә алдагысына синоним буларак кулланалар [2: 217]. Әлеге ике терминны төп билге – аерым урынны географик һәм социаль яктан сыйфатлау уртаклыгы берләштерә. Әдәбиятта җирле

[1] Тәрҗемә мәкалә авторныкы.

халыкның тарихы, яшәү рәвеше, табигый тормыш шартлары, гореф-гадәтләр, башка милләтләр белән аралашып яшәү нәтиҗәсендә формалашкан геройларның үзенчәлекле характер-холкы чагылыш таба.

Бу мәкаләдә Себер төбәге татар әдәбияты милли әдәбиятыбызның үзенчәлекле бер өлеше буларак карала. Илдәге мәгълүм үзгәрешләр XX гасыр ахырында Россиядә яшәүче халыкларның, шул исәптән себер татарларының да, милли әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнүгә, тарихи тамырларын барлауга этәреш ясады. Сүз сәнгатенең нигезе булган туган телне саклау мәсъәләсе регионда бу проблеманың куелышын кискенләштерде. Нәтиҗәдә, дистә елга якын вакыт эчендә Төмән өлкәсе татарларының телен, мәдәниятен, шул исәптән әдәби казанышларын да, тикшерүгә багышланган диссертацияләр язылды, җитди монографик хезмәтләр дөнья күрде [3].

Себер төбәге әдәбиятында дөнья сурәтенең үзенчәлекләрен ачыклау мәкаләнең төп максаты булып тора. Әдәбият белеменә караган фәнни хезмәтләрдә «дөнья сурәте» төшенчәсенә бирелгән билгеләмәләрдә бер-берсенә төгәллек кертелә: «…кешенең үзен әйләндереп алган объектив чынбарлык хакында күзаллаулары бердәмлеге» [4: 231]; «объектив чынбарлыкның кеше тарафыннан тудырылган гомумән дөнья турында, шулай ук, аның аерым бер өлеше хакында кеше кабул итә алырлык бөтен информацияне үзендә туплаган субъектив образы» [5: 177]; «әдәби әсәрдә яки язучы иҗатында аерып чыгарыла торган, чынбарлык хакындагы күзаллаулар системасы» [6: 58]. Соңгы елларда Россиянең төрле халыклар әдәбиятында, шул исәптән татар язучылары әсәрләрендә дә, яңадан тергезелгән дөнья сурәте чагылышын өйрәнүгә багышланган дистәләрчә монографик хезмәтләр басылып чыгуы – сайланган проблеманың кызыклы һәм актуаль булуын дәлилли [7].

XX гасырның икенче яртысында татар укучысына Якуб Зәнкиев исемен таныткан киң эпик планлы «Иртеш таңнары» (1988) [8: 286] дилогиясенең дөнья күрүе Төмән-Тубыл татарлары өчен олы әдәби вакыйга төсендә кабул ителсә, гомумтатар әдәбиятында бу әсәр яңа тема, ягъни Татарстаннан читтә яшәүче татар кавеменең үзенчәлекле дөньясын тәкдир итүче төбәк әдәбияты

үрнәге буларак кызыксыну тудырды. Әдәбиятчы-галим һәм тәнкыйтьче В. Рогачев «Иртеш таңнары» романының рус телендә басылган тәрҗемәсенә кереш сүзендә «...себер татарлары кебек күп гасырлар буенча үз гореф-гадәтләрен, мәдәниятен саклап кала алган халыкның олы хөрмәткә лаек һәм нык нигезле» булуына басым ясап, «мондый халык рухи үзаңның әдәби елъязмасы буларак, үз әдәбиятына лаек» [9: 8], – дип яза.

Романда илебез тарихындагы катлаулы вакыйгалар Себер җирлеге, себер татарлары язмышы аша чагылдырыла, үзенчәлекле геройларның холык-фигыльләре тарихи һәм табигый яшәү шартларында, үзләренә хас гореф-гадәтләре ярдәмендә ачыла. Аерым детальләр, символлар, кабатланмас образлар галереясы романны татар әдәбияты тарихында авыл прозасы тематикасында өйрәнелә торган бихисап әсәрләр арасында танылырлык һәм үзенчәлекле итә.

Гомеренең соңгы елларында иҗат ителгән «Ялкында өтелгән мәхәббәт» (1999) романы авторның милли колоритлы төбәк әдәбияты тудыру юнәлешендәге эзләнүләрен уңышлы дәвам итә. Гомер буе балаларга белем биргән каләм әһеленең үз иҗат җирлегендә язылган 200 дән артык публицистик мәкаләсе һәм фельетоннары да игътибарга лаек.

Я.Зәнкиев иҗатын өйрәнү һәм бәяләү барышында әдәби текстта дөнья сурәте тудыруның үзенчәлекләре турында фикер алышу өчен киң җирлек бар. «Художник чынбарлыкны күрсәткәндә, ул, кичектергесез, аның аңында чагыла. Объектив чынбарлыкның трансформациясе (күчеше) барлыкка килә һәм башка, аннан аерылып торган чынбарлык тудырыла. Бу – нәкъ шушы автор тарафыннан сүз иҗатында тудырылган дөньяның әдәби сурәте була да инде» [10: 4]. Әсәрдә милли менталитет чагылышын, дөньяны кабул итүнең аерым сыйфатларын билгеләү язучының иҗат үзенчәлеген ачыклауга юл ача. Билгеле булганча, «...әдәби әсәрдәге дөнья сурәте, язучының дөньяны индивидуаль кабул итү үзенчәлеген чагылдыра һәм әсәр эчтәлегендә тел чаралары һәм индивидуаль образлылык ярдәмендә тудырыла» [10: 65].

Я.Зәнкиевның ике китаптан торган «Иртеш таңнары» романы Тубыл һәм Иртеш елгалары буенда гомер иткән татар халкының инкыйлаб вакыйгаларыннан алып Бөек Ватан сугышы елларындагы фаҗигале язмышын сурәтли. Әсәрдә язучы авыл җирлегендә кул көче, маңгай тире белән гомер сөргән халык, үз миссиясен халыкка хезмәт итүдә күргән авыл укытучысы язмышларын ил тормышы, тарихи фаҗигаләр аша киң эпик планда күрсәтүгә ирешкән.

Әсәрдә мифологик мотивларга һәм сюжетта кулланылган халык авыз иҗаты элементларына салынган мәгънәви йөкләмәнең функциясен билгеләү себер төбәге әдәбиятында дөнья сурәтенең үзенчәлекле чагылышын ачыкларга ярдәм итә. Бүгенге көнгәчә сакланып килгән гореф-гадәтләр, йолалар, ышанулар халыкның рухи мәдәни байлыгын тәшкил итә һәм сүз, музыка, уен төрләре синтезы буларак карала [11: 5].

Зәнкиев иҗатындагы дөнья сурәтендә фольклоризмның көчле чагылышын ассызыкларга кирәк. Автор үзе дә әсәрләр язу максатын милли рухи кыйммәтләрне, себер татарларына хас булган халык авыз иҗатын теркәп калдыруда һәм аларны киләчәк буынга җиткерүдә билгели [12: 5]. Язучының әсәрләре сюжет канвасына, әсәр текстына кертеп җибәрелгән фольклор жанрларының байлыгы белән аерылып тора. Дилогиядәге себер татарлары тарихына мөнәсәбәтле легенда-риваятьләр, көндәлек тормышындагы гореф-гадәтләр, бу як халкының үзенчәлекле көнитеш тәҗрибәсен туплаган мәкаль-әйтемнәр – барысы да дөнья сурәте тудыруга, геройларның холык-фигылен ачуга хезмәт итә. «Иртеш таңнары» романында тарихи шәхесләр һәм вакыйгалар белән бәйле легенда һәм риваятьләр аеруча әһәмияткә ия.

Ханбикә Сүзге образы – Себер фольклорының иң гүзәл, шигъриятле образларының берсе. Аның турында мәгълүматлар Кунгур елъязмаларында, Г.Ф.Миллернең «Себер тарихы»нда да сакланып калган. Аерым бер чыганакларда, аны Күчем хан Казаннан алып кайткан булса, икенчеләре аның казах илбашы кызы булуы хакында сөйли. Сүзге һәм Күчем хан турында бәян роман-дилогиянең икенче китабында аерым бер бүлекне тәшкил итә. Әсәрдәге

Ялан авылы хронотобы тарихы да әлеге мәшһүр хан образы белән бәйләнгән. Тасвирланган драматик вакыйгалар «Алтын мөгез утравы» хакындагы легенда белән тыгыз үрелгән. Бу легенда XX гасырда хан хәзинәсен эзләүчеләргә дә тынычлык бирми. Төп сюжет линияләренә өстәмә рәвештә тәкъдим ителгән мондый күренешләр әсәр эчтәлеген баета, кызыксыну уята. Шул рәвешле, әсәрдә татар укучысы өчен ятрак, әлегә кадәр таныш булмаган дөнья сурәтләнә.

Я.Зәнкиев иҗатында себер татарларының дөньяга карашын чагылдыра торган тотемистик легендалар да урын ала. Аю баласын күкрәк сөте белән имезеп үстергән хатын турында легенда Себер җирлегендә табигать белән кеше багланышларының бик тирәндә ятуын гына түгел, ә аларның бербөтенне тәшкил итүе хакындагы бик борынгы карашларның яшәп килүен раслый.

Бу үзенчәлек авторның «Ялкында өтелгән мәхәббәт» романында да күзәтелә. «Кызлар тавы» легендасы әсәрнең идея-эстетик катламы белән тыгыз бәйләнгән. Күчем хан сараендагы тоткын кызлар батырлыгы җирле халыкның ирек, азатлыкка омтылыш хисләрен гәүдәләндерүгә хезмәт итә [13: 312]. Төп персонаж Нуриянең токым тарихына нисбәтле сурәтләнгән «яшел күлмәкле кызлар (еш кызлары)» – урман кызлары турында легенда да әсәр сюжеты канвасына уңышлы керешеп китә. Ярыммифологик образлар себер татарлары аңында кешеләр белән янәшәдә – себер урманнарында яши дип кабул ителә; җемелдәп торган яшел күлмәкле бу пәри кызлары, адәми затлар, ир-егетләрне үзләренә гашыйк итеп, урманда калдыралар, алар белән тормыш коралар… Шунысы кызыклы: уйдырма-әкият төсендә бәяләнгән мондый мифологик легендалар XXI гасыр башында да саз артында, тайгага сыенып утырган Себер татарлары тарафыннан чынбарлык буларак кабул ителә.

Халык тормышын тулырак сурәтләү максатыннан, әсәрдә күпсанлы календарь һәм гаилә-көнкүреш йолаларыннан мисаллар китерелә. Бүгенге көндә төрекләрдә «күзең айтын» формасындагы теләк рәвешендә яшәгән гыйбарә Себер татарларында ерак юлдан кайтучы хөрмәтенә үткәрелә торган бәйрәм табыны – «кузайтын» йоласына барып тоташа һәм ул хәзерге көнгәчә сакланган. Автор аны әсәрдә берничә тапкыр телгә ала. Болардан тыш әсәрдә

сынамышлар, табигать көчләре, хайваннар дөньясы белән бәйле ышанулар, ырымнар очрый. Романда туй белән бәйле катлаулы, күп этаплы йолалар тәфсилләп сөйләнә: кыз саучылаудан (сораудан) башлап, туйга чакыту, кияүтабак (кияүне каршы алу), күч күчерү (кызны әти-әнисе өеннән егет өенә озату) һ.б. күренешләр укучыны себер татарларының үзенчәлекле яшәү рәвеше белән таныштыра. «Шушы балам белән авырлы чагымда талымладым да, торна ите ашадым. Алагаем, каты иде ите! Шуңа күрә кызым каты бәгырьле булды»; «Бәби бүләге (төсле озын җепләр) бала үзе дә, аны багарга килгәннәр дә озын гомерле булсынга таратыла»; «Утау басу (яңа өйләнешкән парның түшәгендә алдан бер парны тәгәрәтү) өчен авылның иң тату, бәхетле парын чакырылыр»; «чикләвек уңган елны кызлар кияүгә китә»; «бүрек белән бәреп екмаслык булган кызны элек-электән кияүгә чыгарлык дип санаганнар» кебек мисаллар ышану-ырымнарның сюжет канвасына бик гадәти, реалистик керешеп китүен чагылдыра. «Ат бирсәң – азар, тун бирсәң – тузар, җир бирсәң – мәңгелек булыр», «Эт саркытын арыслан йеймәс», «Атылмаган аюның тиресен бүлешү», «Уттан ерак, судан сак, яманнан читтә бул», «Тигәнгә тиен башы, тимәгәнгә куян башы», «Ирне ефәккә төргән дә, чүбеккә чорнаган да хатын инде», «Кызлы ишек тоткасына кырык ат бәйләнер» кебек мәкаль-әйтемнәр дә себертатар тормышының колоритын чагылдырырга ярдәм итә.

«Ялкында өтелгән мәхәббәт» романында автор тарафыннан поэтик югарылыкта сурәтләнгән ау эте белән аю аулау, сазлыкта үскән, күзләрне камаштырырлык төрле-төрле җиләкләрне җыю, балык тоту күренешләре, җәйге урманда баласын ияртkән поши сурәте, кышкы зәмһәрир суыкта хайваннарына печән салырга чыгучы карт образы һ.б. җирле халык тормышының этнографик сурәтен тәшкил итә.Шул рәвешле, автор тарафыннан үзәктән читтә, урман-сулар, сазлыклар артында гомер кичерүче себер татарлары тормышының әдәби-образлы сурәте тудырыла.

Я.Зәнкиев геройларының рухи дөньясын тулырак чагылдыру максаты белән, аларның көнкүрешен, яшәү шартларын, әйләнә-тирәлекне тәфсилләп сурәтли. Ил тарихын аерым чорда тасвирлау авторга себер хронотобын

тудырырга мөмкинлек бирә. Язучы илебез тарихында булган зур тетрәнүләр вакытындагы татар халкының язмышын Тормышларын бөек максатларга багышлаган катлаулы язмышлар аша киң эпик сурәттә яктыртуга ирешә. Эпик киңлек, зур гомумиләштерүләр, милли-тарихи характердагы мәсьәләләргә мөрәҗәгать итү Я.Зәнкиев әсәрләрен Г.Ибраһимовның «Безнең көннәр» (1934), М.Галәүнең «Болганчык еллар» (1976), Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» (1957), И.Газиның «Онытылмас еллар» (1949-1966), К.Нәҗминең «Язгы җилләр» (1948) кебек танылган татар романнары белән аваздаш итә.

Я.Зәнкиев әсәрләрен анализлау себер татары язучысы тарафыннан тудырылган пространство моделен аңларга юл ачса, мәдәни-тарихи, тарихи-әдәби һәм мифопоэтик контекстларга мөрәҗәгать итү исә әсәрдә авторның тормыш картинасын тудыру үзенчәлекләрен аңларга һәм кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Әдәбиятның лирика төрендә танылып, поэзиягә себер аһәңнәрен алып килгән Булат Сөләйманов та Себер җирлегендә формалаша. Ул иҗатка XX гасырның 60 елларында – әдәбият илдәге мәгълүм үзгәрешләр тәэсирендә күтәрелеш кичергән вакытта килә. Бу чор татар поэзиясе контекстында караганда, Сөләйманов шигъриятенең себер регионында гына түгел, шулай ук гомумтатар әдәби барышында да үзенчәлекле урыны булуы турында нәтиҗә ясарга нигез бар. Әдәби мирасындагы колоритлы поэзия үрнәкләре, тормышының соңгы елларында мәдәният, сәясәт өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлеге шагыйрьне үз иҗат җирлегендә татарның бөек шәхесләре югарылыгына күтәрә. Аның поэтик мирасы, иҗтимагый эшчәнлеге каршылыклы чорда себер татарларын саклауга юнәлдерелгән.

Әдәби эшчәнлегенең башлангыч чорында ук шагыйрь үз иҗатының һәм иҗтимагый эшчәнлегенең кредосын төгәл билгели:

Мин төп себер татарымын чыгышым белән,
Гомер сөргән монда минем бабаларым.
Чал Иртышның үзе кебек, борынгыдан

Мин килмешәк түгел монда, туган җирем,
Гомерлеккә сине ташлап китә алмам.
Җирнең тарту көчен җиңдем, и

Яшәп килә монда татар балалары. Себерем,

Ләкин синең тарту көчең җиңә алмам

[14: 19].

Б.Сөләйманов себер татарларының бу якларда җирле халык, туган җирләре – ата-бабалары туфрагы булуына басым ясый. Иҗатының соңгы елларында аеруча актуальләшкән бу мәсьәлә халыкның үзбилгеләнүе, тарихи үткәнен өйрәнүгә, телен һәм мәдәниятен сакларга омтылыш буларак тагын да көчлерәк, куәтлерәк яңгыраш ала*: «Әйтмәгез, Себерем хакында,/ Үткәндә каргалган җир булган./ Каргалса-каргалсын, ул минем/ Туган җир, и туган…»* [14: 48].

Б.Сөләйманов иҗатының асылы – туган җиренең образлы сурәтен тудыруда билгеләнә. Шагыйрьнең биографиясе, яшәү урыны башка каләм осталарыннан аерылып тора. Әсәрләрендә урын алган татар авыллары исемнәре – Сопра (шагыйрьнең туган авылы исеме, Вагай районы), Бәеш, Рәнцек, Киндерле – себер географиясен тудыруда катнашкан топослар гына түгел, ә татар халкының еракларда килгән тарихын саклаучы төрки атамалар буларак кыйммәтле. Шигъриятендә эреле-ваклы шәһәр, елга, күл исемнәре дә әдәби топос рәвешен ала, көчле позициядә шигырь атамаларына чыгарып, шагыйрь үзәктә яшәүче татар укучысы өчен ят булган яшәү ареалы, үз язмышында эз калдырган дөнья киңлеге белән таныштыра. «Тобол», «Түбән Варта», «Обьта боз киткәндә», «Самотлорда җәй уртасы», «Төньяк, тундра», «Салехардка килгәч» шигырьләрендәге атамалар җансыз топос булудан туктап, җыелма образ – шагыйрьнең кадерле туган җире буларак конкретлаша, символик мәгънәгә ия була башлый.

Шагыйрь иҗатында дөнья сурәте дә гомумтатар әдәби үрнәкләреннән үзгә, үзенчәлекле: «*Чишмәләрең, елгаларың – терекөмеш. / Урманында Еш кызлары яши, имеш, / Кырлар буйлап тәгәрмәчләр / тык-тык үтә, / Гүя алар миңа шуны / хәбәр итә:»Күрәсеңме, саргаешып бетте кырлар, / Туган якка кайтуыңны көтә-көтә!*» [14: 58]. «Еш кызлары» – яшел күлмәкле урман

кызлары турында легенда бу очракта да себер татарының әйләнә-тирәне кабул итү үзенчәлеген күрсәтә.

Сөләйманов иҗатының башлангыч чорында чагылыш тапкан дөнья сурәте себер топосы белән аеруча тыгыз бәйле. Кышкы себер картинасы традицион формада тудырыла: гадәттәгечә, ул салкын, буранлы, карт көртләре астында калган, башка төбәк халкына аңлашылып бетмәгән дөнья төсендә сурәтләнә: *«Караңгылык хакимлеге, Иксез – чиксез кар иле бу...», монда «Ник очрасын хет бер агач. Яңа туган бала кебек, Бу кар иле – шыр ялангач»* («Төньяк. Тундра») [14: 29]. «Очсыз-кырыйсыз кар даласы», «буш киңлекләр», «усал җилләр», «кургаш күк» сурәтләре Себер җиренең караңгы, җансыз ягын чагылдыралар. Шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына хас бу образлылык «Түбән Варта» шигырендә, шушы караңгылыкны җиңеп, яңа шәһәрләр төзүче, нефть чыгаручы кешеләрнең героик образын тудыру өчен антитеза буларак файдаланыла:

Түбән Варта. Июнь ае.
Ә җилләре эттән яман.
Телә кемне талап кала
Кыш сулышын өрә һаман.

Баш өстендә кургаш күге
Пресс сыман җанны сыга
Эйфельмени, саз эченнән
Буровойлар үсеп чыга…
[14: 21].

1970 еллар ахырына Б.Сөләйманов иҗатында табигать күренешләре, пейзаж шушы җирдә яшәгән геройның күңел кичерешләрен ачуга хезмәт итә башлый. Шагыйрь иҗатындагы лирик «мин» субъективлык белән характерланып, сентименталь башлангычны көчәйтә. Себер ландшафтында кыш картинасы да «яктыра», шигырь юлларыннан көлтә-көлтә яктылык сирпелә башлый: *«Челтәр-челтәр ап-ак карлар ява,/ Ап-ак карлар күкнең иңендә»* («Белсәм иде») [14: 102] һ.б.

Шагыйрьнең пейзаж лирикасында тайга төп образ булып тора. Күп очракта ул туган як, туган җир символы гына түгел, ә шунда яшәгән бөтен тереклекнең җыелма образы буларак гәүдәләнә. Тайга, күчерелмә мәгънә алып, дөнья сурәте тудыруга турыдан-туры катнаша. Пейзаж лирикасында лирик

геройның соклану, сагыну кебек хис-кичерешләр белән төгәлләштерелгән туган як табигатенә мәхәббәте чагыла. Күп очракта бу традицион хис туган җиреннән читтә яшәргә мәҗбур булган лирик герой кичерешен күрсәтә: *Мин дә китәм./ Нилэр көтә мине / Туган җирдән читтә, еракта. /Бүген тагын күз яшьләре күрдем /Торып калган ялгыз яфракта*. («Кыр казлары утте кангылдашып») [14: 39].

Туган ягын сагыну тойгысы белән сугарылган әсәрләрендә дә, тайга образы лирик геройны туган иле белән бәйләп торучы үзәк топос буларак тәкъдим ителә. Автор, «туган нигезем», «туган йортым», «бишегем», «бабаларым яткан җир» кебек гыйбарәләрне кулланып, һәр кеше өчен изге булган кыйммәтләрне ача. Мондый характердагы шигырьләрукучы күңелендә психологизм остасы Ә.Еникинең «Туган туфрак» (1959), «Җиз кыңгырау» (1966) әсәрләренә аваздаш хисләр тудыра.

Шагыйрь иҗатындагы аккош образы – татар поэзиясендә ак каен, кыр казлары дәрәҗәсендә торырлык гүзәл символ:

Ак канатлы аккошларым үтте,
Йөрәк яраларым кузгатып.
Бер чылбырга тезеп,
Туган якка
Сагнуларым калдым озатып
«Ак канатлы аккошларым кайта»
[14: 69].

Язгы көннәр, серле төннәр китте
Синең эздән офык артына.
Зәңгәр күктә очкан өметләрем
Аккош булып җиргә атыла.
«Кичен. Аккош күле» [14: 54].

Б.Сөләйманов иҗатында пространстволар каршылыгы еш очрый. «Үзенеке» булган Себер башка урын хронотобына каршы куела. Бу җәһәттән караганда, «Себер – Казан» оппозициясе кызыклы.

И Казаным!
Туган анам кебек, кочагыңа ал син гомергә.
Ярсып чапкан
Минем чал Иртышым
Кушылып аксын синең Иделгә [14: 41].

Шагыйрь иҗатында Казанга багышланган шигырьләр бер циклны тәшкил итә. «Казанга», «Иделдә», «Күптәнме җәй иде Казанда», «Күренми шул Себер Казаннан», «Казаннан китәр алдыннан», «Казанда яз» әсәрләре шундыйлардан. Б.Сөләймановта Казанга тартылу, аны шигърият мәркәзе итеп тану мотивы еш яңгырый. «Тукай кабере янында», «Мин ялгызым йөрим урамда...» әсәрләрендә татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай шәхесе һәм иҗатына мәхәббәт авторның Казанга мөнәсәбәтен ачуга хезмәт итә. Дөньяны шагыйранә кабул итү, күңел кичерешләренең нечкәлеге «Күптәнме җәй иде...» шигырендә дә сурәтләнә:

Күптәнме җәй иде,
Казанда
Кыш иңә күкләрдән ишелеп.
Ду килеп йөримен урамда
Карларның исеннән исереп [14: 49].

Б.Сөләйманов әсәрләрен системалы рәвештә кабул иткәндә, Себер – Казан образлары оппозициядә түгел, ә лирик геройның күңел кичерешләрен гәүдәләндерүче гомуми хронотоп буларак сурәтләнә. Лирик «мин»нең тугын ягын сагыну хисе себер ягының поэтик чагылышы – болан баласы образы – аша оеша:

Күренми шул Себер Казаннан,
Анда карлар, җилләр уйныйдыр,
Ә тайгада болан баласы
Адашкан да ялгыз, елыйдыр.

Шулайдыр ул минем хәлләр дә.
Эзләремне карлар көридер.
Адашкан да тайга эчендә,
Бала чагым елап йөридер [14: 51].

Шагыйрь иҗатында ел фасыллары үзгәрешенең кабатланмас төсләре, колориты аша да үзенчәлекле дөнья сурәте тудырыла: «*Сары сулар / Сары туфрак монда / Бөтен дөнья гүя сап-сары. / Бәлки / Туган якны сагынганга, / Сары булып / Күренәдер миңа нибары*» [14: 62 ].

Аз сандагы гражданлык лирикасы үрнәкләре шагыйрь әдәби мирасында аерылып тора. Б.Сөләйманов иҗатының икенче этабында (1970-1980 еллар) фәлсәфи һәм гражданлык мотивлары көчле яңгырый. Бу чор әсәрләрендә яшәү мәгънәсе хакындагы гамьнәр «үткән-бүгенге-киләчәк» оппозициясендә

яктыртыла. Гомеренең соңгы елларында үзен милли көрәшкә багышлаган шагыйрь милләтнең үзбилгеләнүе хакында көчле публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясый, регионда милли белем бирү системасын тергезү мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән күтәрүчеләрнең берсе дә ул була. Б.Сөләймановның каләмдәшләре Г.Тукай, М.Җәлилгә багышланган шигырьләре шагыйрьнең әлеге көрәш юлындагы уйлануларын һәм теләк-омтылышларын сәнгатьчә гәүдәләндерүгә хезмәт итәләр:

Җилләр сыман йөри,
Илләр буйлап,
Безнең хакта күпме
ялганнар.
Татарлар бит
Фашист балтасына
Баш имәгән өчен ауганнар.

Без иреккә бары
Омтылганбыз,
Омтылмаган беркем
зур данга.
Изелгән дә,
Киселгән дә булган,
Җиңелмәгән
ләкин
дошманга.

Туган ил өчен без
Яуга кергән,
Кергән сыман атлар
бәйгегә.
«Татар илен сатмый»
дип язылган
Төрмә ташларына
мәңгегә [14: 43].

Татар әдәбиятында себер сурәте татар шигърияте ндә Шәүкәт Гаделша тәхәллүсе белән танылган Шәүкәт Сибгатуллин иҗатында тудырыла. (Гаделша – шагыйрьнең әтисе исеме, безнеңчә, шушы тәхәллүсне сайлавы ук булачак шагыйрьнең иҗат кредосын билгели).

Иҗаты белән беренче танышканда ук, Гаделша меңъеллык тарихлы татар шигъриятендә борынгыдан килгән мәҗүси аһәңнәрне кабат яңгыраткан, үзенчәлекле, кабатланмас талант буларак кабул ителә. Әдәби тәнкыйть тә шагыйрь каләменең индивидуальлеген аның дөньяны үзенчәлекле кабул итүендә билгели.

1970 елларда әдәбиятка килгән шагыйрь - әсәрләрендә дөньяга карашның яңалыгы, шәхси-автор сурәтләү чаралары белән каләмдәшләреннән аерылып тора. «Себер татары» [15: 123] шигырендә кулланылган топос шагыйрьнең туган җирен дә, шунда яшәгән халыкның атамасын да белдерә; әсәрдә берничә штрих-сызык белән бик гади һәм, бер үк вакытта, үзгә холык-фигыльле,

дөньяга үз карашы булган себер татары образы тудырыла. Киң күңеллелек бу халыкның төп сыйфаты итеп тәгаенләнә:

Бирәм соңгы серәнкәне[1],
Соңгы телемемне.
Күрәм кеше күңелләрен –
Тыңлап күңелемне.

Кызганмыйм да, үкенмим дә –.
Рәхәтләнеп калам.
Себер татарларын шулай
Яраткан бит Аллам [15: 123].

Үзенең иҗат җирлеген «Казан белән Себер арасы» дип билгеләгән шагыйрьгә шулай да Себер якын: шигырьләрендәге ситуацияләр Себер җирлегендә бара, лирик геройның кичерешләре дә шушы як белән бәйле. Ул үзенең катлаулы язмышы хакында фикер йөрткәндә, нигездә, себер татары позициясеннән чыгып сөйли. Бүгенге көндә Казан каласында яшәвенә нисбәтле булса кирәк, шагыйрь әсәрләре кырыс Себер шартларында гомер кичергән авылдашлары, туган халкы каршында тартыну, ятсыну хисләре белән сугарылган. Якташы Б.Сөләйманов иҗатыннан аермалы буларак, Гаделша әсәрләрендә геройның туган җирен сагыну, җирсү хисләре алар каршында үзен гаепле итеп тою хисе белән үрелгән.

Авылдашларым җылым тарта,
Күл буенда җыйналып,
Кулларымны тыгып кесәгә,
Читтә торам оялып...

Нишләргә? Куллар шома, хәлсез,
Үлгән чабак төсендә.
Шундый куллар белән кайтканны
Монда халык чит итә [14: 32].

Шагыйрьнең лирик герое һәрвакыт эчке каршылыкта яши: туганякларын сагыну, аның рәнҗетелгән, рәхимсез файдаланылган табигате хакында өзгәләнү хисе туган ягыннан аерылганлык, язмыш алдында көчсезлек белән үрелеп, сызлану, әрнү хисе тудыра.

Ш.Гаделша иҗатында дөньяның үзенчәлекле сурәтенә табигатькә үтә сак мөнәсәбәтне гәүдәләндерү аша да ирешелә. Шагыйрьнең күп әсәрләрендә табигать тасвирлары лирик кичерешләрнең фоны, урыны гына булудан туктап, сынландыру алымы аша сызлана, әрни, кичерә торган геройга әверелә. Әсәрләрендәге әрнү шагыйрь иҗатында «табигать һәм кеше» мөнәсәбәтләре

[1] шырпы

чагылышының үзенчәлекле ягын барлыкка китерә. Бу – Гаделшаның шушы кавем вәкиле булуы, себер татарларының яшәү рәвеше һәм дөньяга үзенчәлекле карашы белән аңлатыла. Беренче карашка балаларча самими булган лирик герой алга таба тормыш тәҗрибәсе туплаган аксакал дәрәҗәсендә кабул ителә башлый. Себер табигатенең кире кайтару мөмкинлеге югалган гүзәллеге шигырьләрдәге хисләрнең сәбәбе булып тора: балыксыз күлләр, тапталып, ергаланып беткән тайга, ташландык татар авыллары һ.б. Шагыйрьнең балачак бишегенең бүгенге чынбарлыгы шундый … Аның әсәрләре, язмыш кушуы буенча, ата-бабалары җиреннән аерылган замана кешесе кичерешләрен чагылдыра. Гаделша поэзиясендә токымы, туган туфрагы белән бәйләнешләр да көтелмәгәнчә яңгыраш ала. Лирик герой бөкрәйгән каенга («Зираттагы каен» хәл сорашып сүз кушкач, бәгырьләрне кисәрлек җавап ишетә*:– Атаң бит... Чытырдатып / Тамырдан тарта. / Озак кайталмавыңа / Гарьләнеп ята* [15: 26]. Шагыйрь туган җиренең үткәне шул рәвешле үзенең гаилә тарихына, нәселенә барып тоташа. Ш.Гаделшаның традицион булмаган дөнья сурәтендәге лирик геройның табигатьне ярату, соклану хисләрен чагылдырган үзенчәлекле образлылык тетрәндереп куя: «*Кайсы сазлык суырган, Сукмагын бабамнарның?/ Каенда – сөяк төсе / Күмелеп калганнарның*» [15: 123].

Гаделша шигърияттендәге хайваннар образы тереклекне тудырган Ана архетибы белән бәйләнгән. Болан образы, игътибарны үзенә тартып, себер җирлегенең символик чагылышы буларак кабул ителә. Бер хайванның үлеме автор тарафыннан тормыш бетүгә тиңләнә. Гаделша поэзиясендә урман өчен борчылу мотивы, кызыл җеп булып, шигырьләрне үзара бәйли. «Сагая карт урман», «Элек тә бит, самолетлар очса...», «Урманнарга кабам», «Заман агачлары» шигырьләрендә урман – бербөтен, ә тереклек аның аерым өлешләре төсендә күзаллана. «Поши аткач» шигыренең төп мотивы да шундый:

| | |
|---|---|
| Шундый салкын. | Җылынмый көн, |
| Нарат шартлый. | Нарат шартлый. |
| Эт селәгәе боз булган. | Үзәндә – аксыл томан. |
| Җан чыгарып яткан поши | Үр артында, күпләп атып, |

Җылысына сыенам.
Карт аучылар сөяк чаба –
Өлешләргә бүләләр.
Итне түгел, гуя күчләп
Гөнаһларын өяләр.

Поши туныйлар сыман.
Шумый юкә чаңгыларым –
Табаннарга кан каткан.
Эзәрлекләп гомерлеккә,
Авыр хис кайта арттан [15: 81].

Укучы күз алдында җанны тетрәндерерлек натуралистик картина тудырыла. Аучылык һәм аучы мотивы аша («Йөз яшьлек аучы», «Аучы зары», «Аучы җыры») гөнаһлы җан коючы образы иҗат ителә. Ш.Гаделша шигърияте биографик сыйфатлары көчәйтелгән эмоциональ-психологик лирик герой белән аерылып тора.

Шагыйрьнең «Менә монда болан ауган»; «Башын чуртан судан сонган...» кебек шигырьләрендә тормышның мәгънәсезлеге, аның кешегә дошманилыгы хакындагы экзистенциаль фикерләр җиткерелә. «Болан күзе», «Болан баскан эзләргә», «Кинәт кенә купты давыл», «Сорап куйгалый иде...», «Күл йөрәге», «Карчык зары» әсәрләрендә дә дөньяга үзенчәлекле фәлсәфи караш чагылыш таба. Бушлык, тынлык – Тереклек, яшәү, өмет антитезалары аша укучыга гадәти булмаган фикерләр җиткерелә.

Күл буенда уйный
Сабый болан.
Аның күзләренә
Дөнья тулган.
Ап-ак болыт,
Кояш,
Яшел үлән,
Чишмә,
Чык сафлыгы иңгән.
Кинәт мылтык шартлый,

Яңгырый урман!
Кан чәчрәтеп ава
Сабый болан.
Урман итәгендә
Ана болан.
Аның күзләренә
Ниләр тулган?
Күрә алсагыз әгәр:
Кайгы, яшь юк,-
Дөньябызны йотарлык бушлык!» [15: 30].

Гаделша поэзиясендә реаль табигатьне һәм географик чынбарлыкны кабул итүнең автор аңында художестволы трансформациясе чагыла һәм шул

рәвешле шагыйрьдә натуралистик сурәтлелек, гадәттән тыш кешеләштерү (анимизация) хас булган үзенчәлекле дөнья сурәте формалаша. Аның лирикасында табигатькә мөрәҗәгать итү алымы да еш кулланыла («И табигать, бүген мин...», «Чак кына аңлый алсам мин...», «Сусарларны куып булмый...», «И, бөҗәк», «Аккошларым» һ.б.).

Шагыйрьнең урман, су-күл образлары сурәтләнгән әсәрләренә мифологик фикерләү хас. «Күл йөрәге» шигырендә күлнең тере булуы хакында этник миф трансформацияләнгән. «Карчык зары»нда «кешеләштерелгән» күл образына фани дөнья белән саубуллашкан карчыкның үзенчәлекле мөрәҗәгате тасвирлана. Бу юлларда күлгә – себер халкына гына хас яшәү нигезенә – мөнәсәбәт тә чагылыш таба: *«...И күл! Сине ничек итеп / Күзләремә сеңдерим./ Картым тегендә иң әүвәл / Синең хакта төпченер»* [15: 136].

Тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләргә бәйле әсәрләрдә фәлсәфи уйланулар калкурак чагылыш таба. Шагыйрьләрдәге тарихилык алар иҗатының аерылгысыз эчке хасиятен билгели. Әдәбият белемендә тарихилык аерым бер чорның конкрет-тарихи эчтәлегенең художестволы чагылышы, аның кабатланмас кыяфәте һәм колориты мәгънәсендә карала.

Ш.Гаделша әсәрләрендә себер татарларының үз дәүләтчелекләрен югалтулары фаҗига буларак бәяләнә, себер топосы трагик хронотоп дәрәҗәсенә үстерелә. Бу үзенчәлек шагыйрьнең «Хәзинә», «Күңел елый», «Булмас бүтән уңай вакыт», «Ни диим» һ.б. әсәрләрендә күзәтелә. Себернең үткәне – бүгенге көн хәсрәте, ди шагыйрь. Риторик сорау алымына мөрәҗәгать ителгән «Сазлык» шигырендә автор илнең киләчәге хакында уйлана: «*Мондый сазлар бирәү микән,/ Күп микән? Кемнәр белә? / Бәхет басармы халыкны / Шундый сазлыклы илдә?»* [15: 22].

Ш.Гаделшаның «Бармы ирләр?» шигырендә тарихи шәхес Күчем хан образы милли идеал дәрәҗәсенә күтәрелгән. Тарихи вакыйгалар һәм халыкның бүгенге язмышы хакында параллельләр үткән-бүгенгенең бәйләнышларын ачыкларга ярдәм итә. Трагик тарих шагыйрь иҗатында каршылыклы чагылыш таба. «Себер диләр аны, Себер...» әсәрендә себер төбәгенең табигый

байлыкларына, үткән шанлы тарихына милләтнең өметсез киләчәге каршы куела: «*И Себер татары, ни диим?/ Бары тик Ермакны, Күчемне / Тарихта калдырыр өченме / Дөньяга, бу җиргә син килдең?»* [15: 282] Себер топосы шигырьнең мәгънәви үзәген тәшкил итә. Шагыйрь милләттәшләрен, ваемсызлыктан ваз кичеп, Ермак, Күчем ханнар мисалында, туган җиренең байлыкларын сакларга, табигатен талауга, рәхимсез файдалануга каршы көрәшкә чакыра: *«Күк томан эчендә / «дөп тә дөп», / Тышаулы елгырлар килә күк ./ Әнә шул атларны / Чүктереп атланыр / Берәр ир Себердә / Калдымы?»* [14: 294] Гаделша иҗатындагы хронотопта «тарихи», «индивидуаль» һәм «гомуми», «беркөнлек» һәм «мәңгелек» кебек мотивлар күчеше күзәтелә.

Димәк, Себер төбәге авторлары дөнья сурәте тудыруда төрле алымнарга һәм сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәләр. Себер татарларының психологик портреты, яшәешенең мораль-этик кануннары, әйләнә-тирәгә, аеруча табигатькә үзгә мөнәсәбәте региональ сүз сәнгатенең әдәби сурәте үзәгендә тора. Халык иҗаты җәүһәрләре, төбәкнең бай тарихы һәм шәхесләре, кабатланмас мифологиясе дә дөнья сурәтен баетып киләләр. Моннан тыш тарихи вакыт, эстетик, сакраль вакыт мәгънәсен алып, дөнья сурәте тудыруның актив элементына әверелә.. Халык теленең энҗеләре, сурәтләү чараларына күчеп, оригиналь колорит тудыруга хезмәт итә. Болар себер төбәге татар әдәбиятындагы дөнья сурәтенең үзенчәлеген күрсәтә.

**Әдәбият**


1. *Николюкин А.Н.* Региональная литература // Литературная энциклопедия терминов и понятий / Под ред. А.Н.Николюкина. М., 2001. 1600 с.
2. *Вентцель Т.В.* Местный колорит // Литературный энциклопедический словарь / Под общ. ред. В.М.Кожевникова и П.А.Николаева. М., 1987. 750 с.
3. *Галямова Г.* Отражение темы Сибири в татарской прозе второй половины XX века // Автореф. дис. … канд. филол. наук. Тобольск, 2006. 18 с.; *Муллачанова Г.* Художественный мир татарской поэзии Сибирского региона (1990-2005) // Автореф. дис… канд. филол. наук. Казань, 2006. 27 с.; *Фаизова Л.Х.* Особенности творчества сибирско-татарского поэта Ш.Гадельши // Автореф. дис. … канд. филол. наук. Тобольск, 2006. 24 с.;

*Талипова Г.М.* Тобольский поэт Амдами и его книга наставлений «Насихатнамэ» // Автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2007. 22 с.; *Сурметова Л.Р.* Жанровое своеобразие песенно-музыкальных традиций татар Тюменской области // Автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2007. 27 с.; *Сайфулина Ф.С.* Формирование и развитие татарской литературы Тюменского региона. Тюмень: Вектор Бук, 2007. 296 с.; *Ташкеева Г.Х.* Мифологические и фольклорные мотивы в романах Якуба Занкиева // Автореф. дис. … канд. филол. наук. Тобольск, 2009. 23 с. *Кирамова Х.Х.* Литературно-публицистическая деятельность Якуба Занкиева // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2009. 23с.

4. *Соколовская Ж.П.* «Картина мира» в значениях слов: Семантические фантазии или «катехзис семантики». Симферополь: Таврия, 1993. 231 с.
5. *Геляева А.И.* Человек в языковой картине мира. Нальчик: Каб.–Балк. ун-т, 2002. 177 с.
6. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төз.-авт. Д.Ф.Заһидуллина һ.б. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.
7. *Бусыгина Л.В.*Поэтическая картина мира в лирике Кузебая Герда // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Саранск, 2003; *Сагитова Г.Р.* Художественная картина мира в драматургии Аяза Гилязова // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2007. 27 с; *Халхарова Л.Ц.* Проза Ч.Цыдендамбаева: специфика создания национальной картины мира // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Улан-удэ, 2007. 22 с; *Тухватова Г. Ф.* Художественная картина мира в творчестве Габдулгазиза Мунасыпова // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2011. 22 с.; *Шигалугова З.Х.* Парадигма гендерной художественной картины мира в балкарской лирике 1960-1970-х годов (К.Кулиев – Т.Зумакулова) // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Нальчик, 2011. 22 с.; *Матуева А.Б.* Взаимодействие культурных и этнопоэтических традиций в национальной картине мира бурятских поэтов 1960-1980-х гг. (Лирика Д. Улзытуева, Ц.-Д. Хамаева) // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Улан-Удэ. 2011. 25 с. ; *Ситдикова Ч.Ф.* Принципы и приёмы создания художественной картины мира в прозе Ф. Сафина и Н. Гиматдиновой // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2013. 23 с.
8. *Зәнкиев Я.* Иртеш таңнары: роман. Казан: Тат.кит.нәшр., 1988 – 286 б.
9. *Рогачев В*. В ожидании рассвета // Занкиев Я. Зори Иртыша.-Тюмень: СофтДизайн,1998. 232 с.
10. *Сагитова Г.Р.* Художественная картина мира в драматургии Аяза Гилязова // Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2007. 27 с.; *Воронина Е.А.* Мировоззренческое знание в литературно-художественном творчестве: Дис. … канд. филос. Наук. Нижний Новгород, 2008. 186 с.

11. *Сайфулина Ф.С., Замалиева Л.Ф.* Народный свадебный обряд как литературный первоисточник в татарской прозе // Филология и культура: Казань: КФУ, 2012. №3 (29). С.146-148. http://philology-and-culture.kpfu.ru.
12. *Зәнкиев Я.* Иртеш таңнары: роман. Казан: Тат.кит.нәшр., 1994. 671 б.
13. *Зәнкиев Я.* Ялкында өтелгән мәхәббәт: роман. Төмән, Вектор Бук, 1999. 312б.
14. *Сөләйманов Б.* Мин себер татарымын: шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр / Б.Сөләйманов; Н.Йосыпованың кереш сүзе. Екатеринбург: СВ-96 нәшр., 1998. 256 б.
15. *Гаделша Ш.* Аучы жыры. Казан: Татар кит.нәшр., 2004. 383 б.